РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12,
г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 29 апреле № 27

Түбән Кама шәһәре муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтнең аренда шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәре муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтнең аренда шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп торуның теркәлгән шартларын расларга.
2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2020 елның 29 апрелендәге
27 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама шәһәре муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтнең аренда шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары

1. 2020 елда күчемсез мөлкәттән файдаланган өчен каралган аренда түләвен кичектереп торуның әлеге шартлары «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Федераль законның 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән исемлеге расланган, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә, хәл начарайган шартларда, аеруча зыян күрүче Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм хосусый эшмәкәрләр булган арендага алучылар белән Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек һәм гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул ителгәнгә кадәр төзелгән күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләренә карата кулланыла (алга таба – аренда шартнамәсе, кичектереп тору).

2. Кичектереп тору, торак бинлардан тыш, күчемсез мөлкәткә карата бирелә.

3. Кичектереп тору 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлнең яки югары әзерлек режимы кертелгәннән соң түбәндәге шартларда бирелә:

а) аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да алдарак һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да арттырмыйча, тигез түләүләр белән, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләве күләменең яртысыннан артмый торган күләмдә түләнергә тиеш;

б) кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки югары әзерлек режимы гамәлдә булу срогына тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки югары әзерлек режимы туктатылган көннән алып, тиешле чор өчен 2020 елның 1 октябренә кадәр аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

в) кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

г) кичектереп торуга бәйле рәвештә арендага алучы тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне арендага бирүче тарафыннан билгеләү рөхсәт ителми;

д) кичектерап тору бирелә торган аренда түләве күләме яклар килешүе буенча киметелергә мөмкин;

е) әгәр аренда шартнамәсе белән арендатор тарафыннан коммуналь хезмәтләрдән файдаланган өчен түләүләрне һәм (яки) арендалана торган мөлкәтне карап тоту чыгымнарын аренда түләвенә кертү күздә тотылса, аренда түләвенең күрсәтелгән өлеше буенча кичектереп тору бирелми, әгәр Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки югары әзерлек режимы гамәлдә булган чорда арендага бирүче мондый хезмәтләр өчен түләүдән һәм (яки) мондый чыгымнардан азат ителгән очраклардан тыш.

4. 3 пунктта каралган кичектереп тору шартлары, мондый килешү төзү датасына карамастан, кичектереп тору турында аренда шартнамәсенә өстәмә килешүләргә карата кулланыла.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина